Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы
КАРАР

31.08.2026 №58

Кама Тамагы штп

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының „Кирельский авыл җирлеге“ муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2021елның 4 маендагы 40 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы , Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлегенең генераль планын раслау турында" 2026 елның 14 апрелендәге 689/о номерлы боерыгына туры китереп, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Кирельский авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында " 2021 елның 4 маендагы 40 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль район Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Башлыгы Н.А. Вазыйхов